
## Дельфинарий һәм скалодром



Без җәй көне мәктәп лагерында ял иттек. Лагерьда булганда Биләргә, Аксубайга, Казанга һәм Чаллыга сәяхәтләргә бардык. Кая гына барсак та, автобуста юл буе җырлап барабыз хәзер. Җырлап баргач озын юллар да кыска тоела икән.

Миңа аеруча Чаллыга баруыбыз бик кызыклы булды. Чөнки без анда Дельфинарийдагы дельфиннар чыгышын карарга бардык. Моңа кадәр минем чын дельфинны әле күргәнем юк иде. Тамаша вакытында әлеге хайваннар турында кызыклы мәгълүматлар белән дә таныштык. Дельфиннар бик акыллы җан ияләре икәненә тагын бер кат ышандык. Алар безгә шундый матур номерлар, хәтта җырлап һәм рәсем дә ясап күрсәттеләр. Соңыннан истәлек өчен алар белән фотоларга төштек.



Дельфинарийдан соң апалар безне скаладромга алып барды. Күбебез мондый җирдә беренче тапкыр булуга карамастан, без бер дә арымыйча актив шөгыльләндек. Зур-зур кыяларга бик тиз менеп җиттек. Хәтта анда эшләүче абыйлар да, безнең өлгерлеккә һәм аруталуны белмәвебезгә исләре китте. Яр Чаллы шәһәре буенча экскурсия дә оештырып алдылар безгә. Бигрәк тә зур карусельдән шәһәрне күзәтүе кызык булды.

***Сафиуллина Гөлсем, V сыйныф укучысы***

## / Безнең спорт/



Җәйге каникуллар җиту белән, барлык мәктәп укучылары да ял вакытын көтеп алды. Ләкин спорт сөючеләр өчен каникул да, ял да юк. Җәйге спорт бәйгеләре турында әйткәндә, беренче чиратта, Сабантуйлардагы көрәшне күздә тотабыз. Районыбыз үзәге Аксубайда узган Сабантуйда безнең батырлардан **Камалов Илнур** белән **Сәгъдиев Рәмзис** үз авырлыкларында II урыннарны, **Замалетдинов Зөлфәт** белән**Шичкин Али** I урыннарны яуладылар. Мәләкәс (Дмитровград) шәһәре Сабантуенда **Замалетдинов Зөлфәт** – I урынны, **Шичкин Али**– II урынны алуга ирештеләр.

Әлки һәм Норлат районында узган Республикакүләм “Уяв” чуаш милли бәйрәмнәрендә дә безнең авыл көрәшчеләре катнашты. Шулардан **Замалетдинов Зөлфәт** үз авырлыгында I һәм III урыннарны алуга ирешә. Шулай итеп, узган җәйнең көрәш бәйгеләрендә иң зур уңышка ирешүче Зөлфәт булды.

Шахматчы чемпионыбыз **Гафиятуллин Фаил** өчен дә җәй айлары, күп төрле турнирларда үтә. Моның шулай икәнен без елдан-ел күзәтеп торабыз. Быелгы җәй да искәрмә түгел. Фаил бер-бер артлы килгән шахмат турниларында көч сынашуын дәвам итеп, түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә өлгерде: Республиканың Чистай, Аксубай Сабантуйларында I урын, Мәләкәс (Дмитровград) шәһәре Сабантуенда – I урын; "Большая Кама" республикакүләм турнирында 2008-2013 елгы уенчылар арасында – II урын; Чистай шәһәрендә тиз шахматлар (блиц) турниры буенча – I урын; 17 яшькәчә авыл җирлегендә яшәүче уенчыларның республика беренчелегендә– II урын; шул ук турнирда барлык уенчылар арасында бер үк төрле очко белән II-IV урыннарны бүлеште. Турнирларда Республиканың Казан, Чаллы, Әлмәт, Лениногорск шәһәре һәм төрле районнарыннан көчле шахматчылар катнашты. Фаилгә киләчәктә зур уңышлар, зур җиңүләр теләп калабыз.

## / Котлыйбыз!/



Ямьле җәй айларында туган көннәрен билгеләп үтүче укучыларыбыздан **Замалетдинов Фирдүсне** (02.07), **Сафиуллина Гөлсемне** (09.07.), **Нургатин Фаилне** (27.07)**, Мифтахов Рамазанны** (19.06.),**Сәгъдиев Рәмзисне** (08.08), **Замалетдинов Зөлфәтне** (23.07), **Насыйрова Кәүсәрне** (18.08), **Сафеева Настяны**(29.08), **Гафиятуллин Фаилне** (24.07)**, Галиуллин Әхмәтне** (26.07) котлап, барысының да сәламәт, тырыш, уңган, тәртипле, әти-әниләрнең һәм укытучыларының ышанычын аклаучы булып үсүләрен теләп калабыз!

Мәктәп хезмәткәрләреннән **Насыйрова Гөлүсә, Гафиятуллина Руфия, Сафиуллина Алсу, Сабитова Илсөяр апаларны** да гомер бәйрәмнәре белән котлап, ныклы сәламәтлек, озын гомер, гаилә иминлеге, эшләрендә зур уңышларга ирешүләрен телибез!


**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:**
**Ләйсән Закирова** **Кәүсәр Насыйрова**
**Настя Сафеева** **Гөлсем Сафиуллина**



# Мәктәп хәбәрчесе

**№6**
**(№67)**
**җәй**
**2025 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе газите***



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**


## Зур тормышка – Тукай йортыннан / Безнең сәяхәтләр/



Безнең мәктәптә чыгарылыш сыйныф укучыларына өлгергәнлек аттестатын төрле истәлекле урыннарда тапшыру гадәткә кертелде. Шушы традицияне дәвам итеп, чыгарылыш сыйныф укучыларын, әти-әниләр белән берлектә,Тукай-Кырлайга алып бардык.

Сәяхәт белән берләштерелгән тантаналы чараны дөньяда бердәнбер булган Арча шәһәрендәге “Әлифба” музееннан башладык. Ул музей Арча педагогия көллиятендә урнашкан. Музей җитәкчесе Дамир абый аның тирән тарихы, андагы 300 дән артык төре булган төрле миллә әлифбалары белән таныштырды. Барыбызның да иң тәүге китабы булган “Әлифба” авторлары – Рәмзия Вәлитова белән Сәләй Вагыйзовның тормыш юллары турындагы истәлекләрне дә тыңладык.

Әлифба музееннан соң төп максатыбыз булган данлыклы Кырлай авылына юл тоттык. Монда иң элек Габдулла Тукай музеендагы экспонатлар белән таныштык. Матур итеп бизәлгән Ия елгасы яры буйлап Сәгъди абзый йортына бардык. Нәни Апуш яшәгән йортта иҗатының барлык образлары да ясалган: Су анасы, Шүрәле, Кәҗә белән Сарыгы нәкъ Тукайча! Бу төбәктә Тукай исеме дә, җисеме дә данлыклы икәнлеге күренеп тора. Бөек шагыйребезнең эзләренә басып атлау – чыгарылышлар өчен бер гадәти булмаган тантана иде. Иң дулкынландыргыч мизгел –өлгергәнлек аттестат алуны нәкъ менә Тукай рухы яшәгән төбәктә алу – үзенә күрә бер горурлык та. Чөнки элекке чыгарылышларга аттестат тапшырган Изге Болгар җирендә дә без беренчеләрдән идек. Музейларының тарихында мондый чаралар әле тәүге тапкыр икәнне безгә Кырлайда да әйттеләр. Кырлай буйлап безгә экскурсия оештырган “Шәһри Казан” гәзите журналисты Гөлнур Шәрәфиева безнең мәктәпнең шушы башлангычы турында зур мәкалә дә язып чыгарды.



Көн дәвамында яңгыр явып торуга карамастан, күңел күгебез гел аяз торды. Чарабызны, гадәттәгечә, кумәкләшеп “Туган Тел” җырын башкару белән төгәлләдек. Тукай нигезеннән башланган зур тормыш юлы чыгарылыш укучыларыбызның күңелләрендә якты хатирә булып мәңге калыр.

***Алсу Сафиуллина, XI сыйныф җитәкчесе***

## Уку елы нәтиҗәләре / Рәсми хәбәрләр/

2024-2025нче уку елын мәктәптә 39 бала тәмамлады. Шуларның бишесе чыгарылыш сыйныф укучылары. IX сыйныфта дәүләт имтиханнары нәтиҗәләре буенча уртача билгеләр: рус теленнән – 4,3; математикадан – 5; географиядән – 4; татар теленнән – 5; информатикадан – 5.XI сыйныф буенча имтихан нәтиҗәләре: рус теленнән – 48 балл; математикадан(профиль) – 72 балл; математикадан(база) – 4; биологиядән – 43 балл; җәмгыять белеменнән – 45 балл тәшкил итте.

Барлык укучылар да югары һәм урта һөнәри белем бирү уку йортларының бюджет төркемнәренә урнашты. Йосыпов Рәсим Казан энергитика көллиятендә электрик һөнәрен, Шичкин Али Казан политехник көллиятендә эретеп-ябыштыручы, Нургалиева Ләйлә Түбән Кама медицина көллиятендә шәфкать туташы һөнәрен үзләштерәчәк. Гафиятуллин Самат Казан авыл хуҗалыгы университитендә агроном белгечлеген, Нурматова Зәйнәп Казан медицина көллиятендә шәфкать туташы һөнәрен алачак.

***Сафиуллин Илдар, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

## Балалар Сабан туе – милли тәрбия чарасы




Балаларны иманлы-инсафлы итеп тәрбияләүдә милли эчтәлекле чаралар зур урын биләп тора. Шулар арасында Сабан Туе бәйрәме үзенең күләмлелеге һәм бай эчтәлеге белән аерылып тора. Соңгы елларда бу бәйрәм мәктәп коллективы көче белән оештырылганга, “Балалар Сабан Туе” исеме белән үткәрелә. Шуңа да карамастан, бирегә Түбән Майна халкы һәм шәһәрдән кайтучылар гына түгел, тирә-як авыллардан да кунаклар күп килә. Күңел күтәренкелеге белән укучыларыбыз милли биюләр, җырлар әзерләп, сабан туй түрендә чыгыш ясыйлар. Милли уеннар уйнап, кунакка кайткан балаларны да авыл мохитенең рәхәтлеген күрсәтәләр. Җанлы аралашу, бергәләшеп уйнаулар дуслык, туганлык, кардәшлек җепләрен дә ныгыта. Менә шушы вак-төяк кенә күренгән уеннар да балага никадәр матур истәлек, хәтирә калдыра. Туган як табигате почмагында уздырылган һәр минуты тәрбия бирә.

Әлбәттә инде, Сабан Туе бәйрәмен тиешле дәрәҗәдә уздыру зур әзерлек таләп итә. Мәйданны, күргәзмәләрне  әзерләү, мәдәни чараларны оештыру, нигездә мәктәп укытучылары һәм хезмәткәрләре көче белән башкарыла. Бүләкләр алу өчен чыгымнарны капларга, башка еллардагы кебек үк, мәктәбебезне элек тәмамлаган укучылар нык ярдәм итте. Бәйрәмгә берничә көн кала мәктәп яны лагерена йөрүче һәм бакчада тәрбияләнүче балалар авыл буйлап Саба Туе бирнәсен җыйдылар.

Бирнә җыю –үзе бер зур тәрбияви чара ул. Бу матур йолабыз балалар аңына милли гореф-гадәтләр сеңдерү, аларны авыл халкы белән якынайта, бердәмлеккә, юмарт һәм киң күңелле булырга өйрәтә. Быел да авылдашлар сабыйларның урам буйлап бирнә җыеп килүен турыларында милли тәм-томнар белән чәйләр әзерләп көтеп тордылар. Колгага чиккән сөлгеләр янына бүләкләрен бәйләп, изге теләкләрен әйтеп җибәрделәр.



Быелгы Сабан Туе, көне шулай туры килгәнлектән, Корбан Гаете хөрмәтенә үткәрелде. Бәйрәм балаларның азан әйтүе һәм Коръән уку белән башланып китте. Бәйрәмнең рәсми өлешендә балаларны котларга килгән мәртәбәле кунакларга сүз бирелде. Районның мәдәният өлкәсе җитәкчесе Тимирясев Алексей Сергеевич, Биләр урманчылыгы җитәкчесе Рамил Равил улы Нуруллин, Аксубай спорт мәктәбе директоры Радик Касыйм улы халыкны бәйрәм белән котлап, Сабан туен оештыручыларга рәхмәт хатлары һәм бүләкләр тапшырдылар. Алардан соң сүз алган мәктәбебез директоры Насыйров Рафик Гомәр улы узган уку елында укуда, район һәм республикакүләм дәрәҗәдә уздырылган спорт ярышларында, әдәби һәм сәнгати бәйгеләрдә алдынгы урыннар яулаган укучыларны билгеләп үтте. Мәчеттә балалар өчен дин дәресләрен алып барган Сәкинә һәм Ильһамия апаларга рәхмәт белдерелеп бүләкләр бирелде.

Рәсми өлештән соң балалар өчен дә төрледән-төрле Сабантуй уеннары оештырылды. Ярышларда катнашучыларның берсе дә бүләксез калмады. Уеннар балаларның матур тамашалары, җыр-биюләре белән үрелеп барды. Бәйрәм ахырында балалар корбан итеннән пешерелгән пылаудан һәм шашлыктан авыз иттеләр, тәм-томнар белән сыйландылар. Инде менә Сабан Туеның иң төп бәйгесе – милли көрәшкә дә чират җитте. Көрәштә үзебезнең мәктәп укучыларыннан тыш, аларга теләктәшлек белдереп Аксубай бистәсеннән килгән иптәшләре дә катнашты. Ул көнне күп җирләрдә Сабан Туйлары уздырылганлыктан, узган еллардагы кебек башка районнардан килүчеләр булмады. Төп батыр булып, моннан ике ел элек тугызынчы сыйныфны тәмамлап, хәзер Яр Чаллы шәһәрендә белем алучы көрәшче егетебез Галимов Рияз калды.



Аллы-гөлле итеп бизәлгән мәйдан Чирмешән буендагы матур тугайга ямь, нур биреп торды. Бәйрәмдә катнашучыларның күбесе дини кануннарга туры китереп, милли киемнәрдән килүләре дә бәйрәм рухын баетты. Көн дәвамында килгән кунаклар күңелләрен милли һәм дини рухта “агартты”. Иманлы яшь буын тәрбияләүдә мондый чараларның әһәмиятен танып, дәвамлы, нәтиҗәле булса иде дигән теләк-фикерләре белән уртаклашты.

Бәйрәм тәмамлангач, мәйданны күтәренке күңел белән җыештырып та алдык. Мондый чара бер генә балада да эзсез калмас, туган авыллары биргән җылылык, ярату, алар өчен оештырылган чара йөрәкләрендә матур истәлек булып сакланыр. Алдагы көннәрдә дә, яңадан-яңа фикерләр туып, тагын да отышлырак чаралар оештырырга язсын дип калабыз.***Фәнүзә Гафиятуллина*, *баш мөхәррир***



## “Дуслык” лагере – үсеш ноктасы



Җәй ул – күңелле  ял, маҗаралар һәм яңа ачышлар вакыты. Һәм боларның барысын да безнең мәктәп лагерында табарга була. Мондагы  һәр көн якты вакыйгалар, кызыклы танышулар һәм файдалы күнекмәләр белән тулы. Тәрбиячеләр лагерьда узган һәр көнне мавыктыргыч һәм кабатланмас итеп ясарга тырыштылар. Балалар төрле һөнәрләр белән таныштылар, иҗат дөньясына чумдылар, авылыбызның тирә-ягын ныклап өйрәнделәр.

Төрле һөнәр ияләре белән очрашулар аеруча кызыксыну уятты. Балалар чын табибның сөйләгәннәрен кызыксынып тыңладылар, беренче ярдәмне ничек күрсәтергә икәнен белделәр. Тимерче белән очрашу да шундый ук соклану уятты. Ул металл белән эшләүнең чын осталыгын күрсәтте. Ә балалар аңа ярдәм итеп, үзләрен осталар ролендә сынап карый алдылар. Агач остасына баргач та гаҗәеп уңганлыкның шаһиты булдык. Ул гади агач кисәгеннән матур һәм кирәкле әйберләр ясалуын күрсәтте. Балаларга мастер-класс та оештырды. Укучылар үзләре дә агач белән эшләп карадылар. Балалар пешекче  һөнәре белән якыннан таныштылар. Үзләре дә, бу рольга кереп, төрле ризыклар пешерү серләрен ачтылар. Укучылар өчен, аеруча, үзебезнең милли ризыгыбыз – өчпочмак пешерү кызык булды. Шаурма, гамбургер, пица кебек яңа ризыкларны әзерләүдә дә яшь пешекчеләребез актив булдылар.

Лагерь вакытында авылыбыз тарихын һәм аның тирә-ягындагы топонимик атамаларны өйрәнү буенча да зур көч куела. Авыл тирәсендә булган күлләр, елгалар, болынныр чишмәләр буенча экскурсияләргә чыктык. Җирле атамаларның килеп чыгу тарихларын өйрәндек.

Сәяхәтләребез авыл һәм аның тирә-ягы белән генә чикләнеп калмый әлбәттә, зур шәһәрләргә дә бик теләп чыктык. Башкалабыз Казаннны бер елны да калдырганыбыз юк дисәк тә була. Бу елны укучыларга Чаллы шәһәренә кунакка барырга насыйп булды. Мондый сәфәрләр күңел ачу гына түгел, ә балаларга дөньяны бөтен матурлыгы һәм төрлелеге белән ачарга ярдәм итә торган белем һәм тәрбиянең мөһим өлеше булып тора.



Беренчедән, экскурсияләр тарихны "тере килеш" күрергә мөмкинлек бирә. Дәреслектәге коры фактлар урынына, балалар, борынгы биналарга, һәйкәлләргә һәм музейларга барып, үткәннәрнең атмосферасына чума. Икенчедән, бу башка шәһәрләр һәм халыкларның мәдәнияте һәм традицияләре турында белү өчен бик яхшы ысул булып тора. Моннан тыш, экскурсияләр кызыксынучанлыкны үстерә һәм дөньяга карашны киңәйтә. Ниндидер яңа һәм кызыклы нәрсәләрне күргәч, балалар сораулар бирә, җаваплар эзли һәм укуга кызыксыну күрсәтә башлыйлар. Һәм, әлбәттә, мондый сәфәрләр дуслык мөнәсәбәтләрен ныгыта.

Лагерь вакытында патриотик тәрбия турында да онытмыйбыз. Ел саен “Хәтер һәм кайгы көнен” зурлап билгеләп узабыз. Быел әлеге көнне авылыбыздагы сугыш чоры балалары белән очрашу оештырылды. Укучылар өлкәннәрнең сугыш чоры турында сөйләгән сүзләрен игътибар белән тыңладылар, сораулар бирделәр. Мондый очрашулар аша балалар хәзерге тыныч һәм тулы тормышның рәхәтен күрергә өйрәнсәләр иде.

Лагерьдагы иң файдалы көннәрнең берсе дип “ Тәҗрибәләр көнен” әйтергә була. Бу көнне балалар, аеруча, зур түземсезлек белән көтеп алдылар. Әлеге көнне мәктәбебезнең химия һәм биология укытучысы Рифкать абый балаларга бик кызык һәм мавыктыргыч тәҗрибәләр күрсәтте. Күрсәтеп кенә дә калмады, ни өчен шундый реакцияләр килеп чыгуын да аңлатып барды. Тормышта кирәкле киңәшләрен  дә җәлләмәде.

Һәм, әлбәттә, лагерьдагы һәр көн кызыклы уеннарга бай булды. Саф һавада хәрәкәтчән уеннар, интеллектуаль викториналар, иҗади конкурслар – болар барысы да физик һәм акыл сәләтләрен үстерүгә ярдәм итте, шулай ук дуслык мөнәсәбәтләрен ныгытты.

“Дуслык” лагере – балалар җәй көне вакыт үткәрә торган урын гына түгел. Биредә үсеш, практик белемнәрне арттыру, тормышны өйрәнү һәм сәламәтләндерү өчен уникаль мөмкинлекләр ачыла. Бу якты тәэсирләр, яңа белемнәр һәм онытылмас хис-кичерешләр урыны. Аларны балалар җылылык һәм елмаю белән искә алачак. Һәм безгә, оештыручыларга, җәйге лагерь тәҗрибәсе ярдәмендә балаларыбызның ничек итеп үсеш алуын күзәтү бик күңелле.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***

## *Әти-әниләрдән рәхмәт сүзләре*

Әлхәмдулилләһи, шундый күңелле, файдалы, кызыклы лагерь көннәре сизелми дә үтеп китте. Бу көннәрдә алган тәэсирләр балалар күңелендә бик озак яңгырап торыр әле. Мин үзем лагерь тәрбиячеләре куйган видеоларны мактанып әллә кемнәргә җибәреп бетердем. Күрегез, менә ничек тә эшләп була, үрнәк алыгыз дип. Шундый кызыклы лагерь тормышы оештырганыгыз өчен мәктәп директорына, лагерь җитәкчесенә, тәрбияче һәм пешекче апаларга бик зур рәхмәтебезне җиткерәбез. Гаиләләрегезгә иминлек, саулык-сәламәтлек, барча эшләрегезнең дә гел уңышлы гына баруын теләп калабыз. Без балаларыбыз белән бу көннәрне сагынып искә алырбыз. Тынычлап, матур итеп ял итәргә насыйп булсын иде алдагы көннәрдә дә.

***Ландыш Галиуллина, Такталы авылыннан***

***/ Балалар иҗаты/***

## *Лагерь тизрәк башлансын иде*



Җәйге мәктәп лагеренда мин инде икенче тапкыр ял иттем. Быелгы лагерьны мин бик түземсезлек белән көтеп алдым. Лагерь бездә бик күңелле үтә, чөнки без төрле шәһәрләрне барып күрәбез. Шул сәяхәтләрнең берсен сезгә дә сөйләп китәсем килә. Яңгырлар явып торуга карамастан, без бер көнне Казан шәһәренә киттек. Барып җиткәч, иң элек Казанның фән һәм техника йортында булдык. Бирердә төрле мавыктыргыч тәҗрибәләр үткәрелә торган бик күп фәнни экспонатлар бар икән. Монда без үзебезне галимнәр, уйлап табучылар кебек хис иттек. Үзем өчен мин бирердә бик күп ачышлар ясадым.

“Сөембикә” кафесында ашап чыккач, без Казанның Җиңү паркына киттек. Мин анда күп төрле танклар, самолетлар, вертолетларны күрдем, алар янында фотога төштем. Аннан соң без аннан кинотеатрга “Аждаһаны ничек кулга ияләштерергә” диелгән фильм карарга бардык. Моңа кадәр беркайчан да кинотеатрда булганым юк иде. Залдагы утлар сүнгәч, үзеңне фильм эчендә кебек хис итәсең. Шуңа күрә кинотеатрда фильм карау бик ошады.

Җәйге лагерьда булганыма мин бик шат. Чөнки лагерьдагы сәяхәтләрбик кызык үтте. Киләсе ел лагеры тизрәк килеп җитсен иде.

***Хәйруллин Мансур, III сыйныф укучысы***

## *Чәчәбиме – Ясәвиме?*




Безнең җәйге каникуллар һәр елны мәктәп лагеры белән башланып китә. Лагерьда вакыт бик күңелле уза безнең өчен. Бигрәк тә миңа авылның тирә-ягына чыккан көннәр ошый.

Шулай бер көнне без лагерь белән Чәчәби тавына экскурсиягә бардык. Ул бик матур, җылы һәм кояшлы иде. Чәчәби тавы Чирмешәннең аргы ягында. Елга аркылы буа булмаганлыктан суны ерып чыгарга туры килде. Тауга барып җиткәч без рәхәтләнеп җиләк ашадык, тау битеннән торып табигатьне күзәттек. Кызлар төрле-төрле матур кыр чәчәкләре җыйды. Килеп җитүгә үк тау астындагы Чәчәби чишмәсеннән туйганчы су эчтек. Апалар безне чишмәнең ни өчен шулай аталганы турында сөйләделәр. Элек заманда безнең авылда Ясәви исемле бер кеше яшәгән икән. Көннәрдән бер көнне ул Изгар авылындагы боярның утарын яндырган. Шуннан соң аны тотып Себергә сөрергә кушыла. Себергә озатканда Ясәви качып китә һәм Чуаш әрәмәсендә качып яши башлый. Чуашлар Ясәвине “Чәчәби” дип атаганнар. Шул сәбәпле андагы тау һәм чишмә “Чәчәби тавы”, “Чәчәби чишмәсе” исем белән атала башлый.

Менә шул тарихларны тыңлап, тау битендә уйнаганнан соң без гөмбә җыя-җыя мәктәпкә кайтырга чыктык. Гөмбәбез дә шактый җыелды. Икенче көнне ул гөмбәне пицца ясаганда кулландык.

Авыл тирәсеннән аккан Чирмешән елгасы буена да апалар безне еш алып бара. Монда без балык тотабыз, елга буенда булган әкәм-төкәмнәр, үсемлекләр, дару үләннәре белән танышабыз. Бик эссе көннәрне коенып та алабыз.


Менә шулай күңелле һәм файдалы уза безнең “Дуслык” лагерында көннәр. Сез дә безгә ял итәргә килегез!.

***Закиров Инсаф, V сыйныф укучысы***

***/ Чал тарихта эзле без!/***

## *Авылыбыз тирәсендәге тарихи күлләр*

Авылыбыз тирәсендә шактый санда күлләр булуы барыбызга да билгеле. Бу язманы әлеге күлләрнең атамаларының килеп чыгышына, аларның үткәндәге хәле һәм бүгенге көндәге торышына багышларбыз. Гәзитнең бу санында Чирмешәннең аргы ягында урнашкан, атамалары күршедәге чуаш халкына бәйле булган күлләргә бирелер.




### *Пәдер күле*

Пәдер күле элекеге чуаш зираты турысында, Чирмешән үзәненең текә яры астында урнашкан. Күлнең атамасы анда Пәдер исеме чуаш батып үлгәнлектән килеп чыккан.

Элек авыл Югары кырда булганда анда татарлардан кала чуашлар да яшәгән. Әлеге чуашларның бабалары авылга XVIII гасыр башында ачлык вакытында Самара ягыннан килеп урнашканнар. Риваять буенча, шул чуашларның Пылак исемлесе безнең авылда каласы килмичә күченеп китә, һәм хәзерге Алексеевск районындагы Тигән-Болак авылына нигез сала. Бу Пылакның Пәдер исемле улы туганнарын күрергә дип безнең авылга килгәндә фаҗигага юлыга. Ул заманда күл турысында Югары кырдан төшә торган юл булган. Шул юлдан килгәндә Пәдер атларын тыя алмыйча, текә ярдан туры төшеп китеп күлгә баткан. Атлары, тарантасы белән батмыйча чыга алганнар, ә Пәдер үзе батып үлгән. Шушы мәгълүматлардан чыгып, “Пәдер күле” атамасы 1730-1740 еллардан бирле кулланылышта йөри дип әйтә алабыз.

Картлар телендә Пәдер күле бик тирән, хәтта төпсез икән дип сөйләнелә. Имештер, анда батып үлгән Пәдерне эзләгәндә 9 дилбегәне бер-берсенә бәйләп күлнең тирәнлеген үлчәгәннәр, әмма төбенә җитә алмаганнар. XIX гасыр урталарында Пәдер күле Чирмешән суы белән тоташкан булган. Аларны тоташтырган сыза хәзер дә беленеп тора, әмма Чирмешән сулары күлгә язгы ташу вакытында гына агып керәләр. Пәдер күленең тирәнлеге дә элеккеге кебек түгел, иң тирән җирендә дә кешене күмә алмый. Шулай да аның суы кипмичә ел әйләнәсендә тора.

### *Келәүле күл*

Югары кырдан Чәчәбигә җиткәнче Чуаш әрәмәсе башланган җиргә төшүче ерганакның киңәеп торган өске өлеше “Келәүле күл” дип атала. Элек бу җирдән Югары кырның өске өлешен биләп торган урманның кырые үткән һәм ярларында калын агачлар үскән бер күл булган. Хәзерге вакытта әлеге күлнең урыны гына чокыр булып беленеп тора. Күлдән аска төшкән ерганак соңрак барлыкка килгән. 1854 елгы планда ул урында өсте тоташтан чәчелә торган иңкүлек күрсәтелгән.

“Келәүле күл” атамасы чукынмаган, ягъни чын чуашлар башкара торган йолага бәйле. Элек чуашлар йолаларын “кирәмәт” дип атала торган махсус урыннарда башкарганнар. (“Кирәмәт” төшенчәсе гарәп телендәге “кәрамәт” сүзеннән килеп чыгышлы. Аллаһы Тәгаләнең юмартлыгы, могҗиза дигән мәгънәне аңлата). Кирәмәтләр гадәттә урман буенда, һичъюгы, бер яки берничә зур агач үскән урыннарда корылган. Моның өчен дүртпочмаклы мәйданны киртәләр белән тотып алып, төньяк, көнчыгыш һәм көнбатыш якларында капкалар калдырганнар. Көнбатыш капкадан кешеләр кергән, көнчыгышыннан корбанлык хайваннарны, төньяктагысыннан су керткәннәр. Көнчыгыш капка янына өч багана утыртылып аларның берсенә корбанлык өчен китерелгән атны, икенчесенә сыер яки үгезне, өченчесенә сарыкларны бәйләгәннәр. Чуашлар дуңгыз асрасалар да, аны корбанга яраксыз санаганнар. Көнбатыш капка янында хайван чалу һәм казан асу урыннары, ә төньякта ашар өчен өстәл көйләнгән булган. Юмзя дип аталучы йолачы корбаннарын чалганнан соң, итләрен шунда ук пешереп ашаганнар. Ашау тәмамланганнан соң барысы бергә көнчыгыш якка карап басып келәү әйткәннәр, ягъни теләк теләгәннәр. Келәүнең эчтәлеге шундыйрак булган: *“Кичер ах Туры. Нәрсә телим шуны бир. Икмәк бир, терлекне күбрәк бир, балалар бир Туры. Нәрсә телим шуны бир. Акча бир күбрәк. Амин”.* Шул келәүне әйтеп озак вакыт тын торганнан соң, җиргә тезләнеп өч тапкыр сәҗдә кылганнар. Шуннан соң тагын бер кат утырып ашап яңадан келәү әйткәннәр.

Мондый йолалар гадәттә табигый бәла-казалар, иген уңмау сәбәпле, яки иген уңышын җыеп алганнан соң Ходайга рәхмәт белдерү максатыннан үткәрелә торган булган. Йола башкаруда өлкән яшьтәгеләр генә катнашкан. Келәүнең җомга көн уздырылуы, сәҗдә кылу, дуңгызны корбанга чалмау чуашларга татарларның мәдәни йогынтысы көчле булганлыгын күрсәтә.

Келәүле күлдәге агачлар череп ауганнан соң кирәмәт Чуаш Майнасының хәзерге су суырту манарасына якын торган ялгыз агач янында корыла.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы тарих фәннәре кандидаты***